ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**23.08.2021**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2039**

Яңа редакциядә Зеленодольск муниципаль районының Мактау тактасына урнаштыру өчен кандидатларны раслау буенча комиссияне раслау турында һәм 2020 елның 10 августындагы «Зеленодольск муниципаль районының Мактау тактасы турында» 1453 номерлы Карарының 1 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында

Кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә һәм тиешле тәртипкә китерү максатыннан, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 10 августындагы «Зеленодольск муниципаль районының Мактау тактасы турында» 1453 номерлы карары белән төзелгән, Зеленодольск муниципаль районының Мактау тактасында урнаштыру өчен кандидатларны раслау комиссиясе составын, әлеге Карарга 1 нче кушымта рәвешендә, яңа редакциядә расларга.
2. «Зеленодольск муниципаль районының Мактау тактасы турында» 10.08.2020 ел, № 1453 Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына 1 нче кушымтадагы Зеленодольск муниципаль районының Мактау тактасы турында нигезләмәнең 1.3 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Мактау тактасына урнаштыру өчен кандидатуралар Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты төзегән, Зеленодольск муниципаль районының Мактау тактасында урнаштыру өчен кандидатларны раслау комиссиясе тарафыннан карала һәм Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы карары белән раслана».
3. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе И. Р. Ганиев

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
23.08.2021 № 2039
1 нче кушымта

Зеленодольск муниципаль районының Мактау тактасында урнаштыру өчен кандидатларны раслау буенча комиссия
СОСТАВЫ

| № | ФИАт.и | Вазифа атамасы |
|---|---|---|
| 1 | Ганиев И. Р. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе |
| 2 | Лулаков Д. В. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, рәис урынбасары |
| 3 | Устинова С. А. | «Зеленодольск муниципаль районы музей берләшмәсе» муниципаль бюджет учреждениесе директоры, секретарь (килешү буенча) |
| Комиссия әгъзалары | | |
| 4 | Кадникова Э. Р. | Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| 5 | Старостин А. В. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары |
| 6 | Сафиуллина Г. Р. | Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының оештыру бүлеге начальнигы (килешү буенча) |
| 7 | Чибрикова Р.Н. | Җәмәгатьчелек белән элемтәләр буенча белгеч |
| 8 | Гыйззәтуллин Т. Р. | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы ветераннар (пенсионерлар) җирле иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| 9 | Потапова М. Э. | Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының кадрлар сәясәте бүлеге начальнигы урынбасары (килешү буенча) |
| 10 | Майорова Е. А. | Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты эшләре белән идарә итүче |
| 11 | Афанасьева Р. В. | Җитәкче урынбасары - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе начальнигы |
| 12 | Купоросова О. В. | Зеленодольск муниципаль районы Иҗтимагый Советы рәисе (килешү буенча) |